ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.08.2017 Казан ш. № 10-18/кс

«ЭКО» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм су бүлүгә тарифлар билгеләү хакында.

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы «ЭКО» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен, шушы карар кушымтасы нигезендә календарь буенча бүлеп, эчә торган суга һәм су бүлүгә тарифлар билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2017 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы «ЭКО» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 11.08.2017
№ 10-18/кс карарына
кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы «ЭКО» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен салкын су белән тәэмин итүгә һәм су бүлүгә тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб м. | Су бүлүгә тариф (бер ставкалы), сум/куб м. |
|---|---|---|---|
| | | Карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2017 кадәр | Карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2017 кадәр |
| | Питрәч муниципаль районы | | |
| 1 | «ЭКО» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 25,97 | 26,09 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге